| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА НОВОТУМБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ТУМБА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

Яңа Тумба авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Яңа Тумба авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Совет урамы буенча 25нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Шоссе урамы буенча 1нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2019 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Бакча урамы буенча 3нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Яңа Тумба авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле

әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Тумба авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Осипов